РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Енабердинского сельского поселения Менделеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге Советы

---

Р Е Ш Е Н И Е

К А Р А Р

22 ноябрь 2024 ел

№135

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының "Енабердино авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә туристлык салымын билгеләү һәм гамәлгә кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 33.1 бүлеге, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә туристлык эшчәнлеге нигезләре турында» 1996 елның 24 ноябрендәге 132-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы  Енабердино авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Енабердино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә 2025 елның 1 гыйнварыннан түләүгә мәҗбүри булган туристлык салымын билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Физик затларның вакытлыча яшәү өчен урыннар бирү буенча күрсәтелә торган хезмәт хакының процентларда түбәндәге салым ставкаларын өстәлгән бәягә салым һәм салым суммаларын исәпкә алмыйча билгеләргә:
2025 елда- 1 процент;
2026 елда - 2 процент;
2027 елда - 3 процент;
2028 елда - 4 процент;
2029 елда - 5 процент.

3. Санатор-курорт дәвалануы буенча хезмәтләр күрсәтелә торган урнаштыру чаралары буенча туристлык салымы яшәү тәүлегенә 100,00 (йөз сум 00 тиен) минималь салым күләмендә түләнә.

4. Салым түләүчегә Россия Федерациясе Салым кодексының 418.4 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән физик затның тиешле статусын раслый торган документлар бирү шартларында салым базасына вакытлыча яшәү буенча хезмәт күрсәтүнең бәясе кертелми.

5. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә дип билгеләргә.

**6.** Әлеге карарны Енабердино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http//pravo.tatarstan.ru  һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru «Енабердино авыл җирлеге» бүлегендә бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Енабердино авыл җирлеге Советының финанс-бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Енабердино авыл җирлеге Советы рәисе Е.Ю.Скворцова